СОВЕТ
СЕЛО-УБЕЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Мира, дом 40, село Новый Убей,
Дрожжановский район 422464

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тынычлык урамы, 40 нче йорт, Яна Уби авылы,
Чүпрәле районы 422464

Тел.: (84375) 3-55-35, 3-55-36, e-mail: Subey.Drz@tatar.ru,
www. subey -drogganoe.tatarstan.ru

---

с. Новый Убей

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 13 декабре №51/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Советының 11.11.2019 елның 62/2 номерлы «физик затлар мөлкәтенә салым турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Уби авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2019 № 62/2 карарына (21.05.2020 № 74/2, 15.11.2022 №28/2, 09.10.2023 № 38/1, 24.09.2024 № 48/1 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 4 пунктта:**

**5 пунктчада** «, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнарны»сүзләрен өстәргә;

**7 пунктчада** «, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнарны " сүзләрен өстәргә.».

**2) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Салым ташламасы РФ Салым кодексының 406 статьясының 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарыннан һәм РФ Салым кодексының 406 статьясының 2 пунктының 2_1 бүлегендә урнашкан урыннардан тыш.».

2. Әлеге карарны Уби авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Уби авыл җирлеге сайтына урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасының гамәлдә булуы 2023 елгы салым чоры һәм аннан соңгы салым чорлары өчен җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Уби Авылы Башлыгы
авыл җирлеге: А.П. Ярухин